# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

## Татарстан Республикасында чит ил инвестицияләре турында

Әлеге Закон Татарстан Республикасы халык хуҗалыгына чит ил капиталын җәлеп итүнең хокукый, икътисадый һәм җәмгыяви шартларын билгели. Ул чит ил инвесторларының хокукларын тәэмин итүгә һәм мөлкәти, финанс, акыл милекләрен саклауга юнәлтелгән.

### 1 бүлек

### Гомуми нигезләмәләр

<u>1 статья</u>. Чит ил инвестицияләре турында законнар

Татарстан Республикасы территориясендәге чит ил инвестицияләре белән бәйле мөнәсәбәтләр әлеге Закон һәм Татарстан Республикасы территориясендә гамәлдә булган законнар нигезендә хокукый җайга салына.

Әгәр Татарстан Республикасы территориясендә гамәлдә булган халыкара шартнамәдә әлеге Законадагыдан зермалырак башка

кагыйдәләр салынган булса , ул вакытта халыкара шартнамә кагыйдәләре кулланыла.

2 статья. Чит ил инвестицияләре һәм инвестиция эшчәнлеге

Чит ил инвестицияләре табыш (керем) алу максатларында эшкуарлык эшчәнлегенең һәм эшчәнлекнең башка төрләренең объектларына чит ил инвесторлары тарафыннан кертелүче мөлкәти һәм акыл байлыкларының барлык хәзинәләрен үз эченә ала.

Мондый хәзинәләр түбәндәгеләр булырга мөмкин:

- матди һәм матди булмаган активлар;

- акча, максатчыл банк кертемнәре, акцияләр, облигацияләр һәм башка кыйммәтле кәгазьләр.

Инвестиция эшчәнлеге - чит ил инвестицияләренең әлеге Законда каралган теләсә кайсы төрен тормышка ашыруга юнәлгән гамәлләр җыелмасы ул.

Инвестиция эшчәнлегенең хокукый нигезе шартнамә була.

Ирекле икътисадый зоналарда инвестиция эшчәнлеге Татарстан Республикасының махсус законы тарафыннан җайга салына.

Чит ил инвесторлары белән Татарстан Республикасы территориясендә гамәлдә булган законнар нигезендә килешүле (концессион) һәм башка шартнамәләр төзелергә мөмкин.

3 статья. Чит ил инвесторлары

Түбәндәгеләр Татарстан Республикасының чит ил инвесторлары була алалар:

- чит илләрнең хокукый затлары, моңа үзләре урнашкан

илләрнең яисә үәләре теркәлгән илләрнең законнары нигезендә инвестицияләрне башкару өчен төзелгән һәм шуңа тулы хокукы булган теләсә нинди компанияләр, фирмалар, предприятиеләр, банклар, оешмалар, шулай ук аларның берләшмәләре керә;

- хокукый зат хокуклары булмаган һәм үәләре урнашкан яисә теркәлгән ил законнары нигезендә төзелгән һәм инвестицияләрне башкару хокукы булган чит ил берләшмәләре;

- чит ил гражданнары, шулай ук чит илдә (Россия Федерациясе чикләреннән тыш) даими яшәү урыны булган Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясе гражданнары, Татарстан Республикасы законнары нигезендә гражданлыксыз затлар дип танылучылар, гражданлыгын алган илдә яисә даими яшәү урынында аларның хуҗалык эшчәнлеге белән шөгыльләнер өчен теркәлгән булулары шарт;

- халыкара оешмалар һәм фондлар;

- чит дәүләтләр.

<u>4 статья.</u> Чит ил инвестицияләренең объектлары

Республика икътисадының барлык тармакларындагы һәм өлкәләрендәге яңа гына төзелгән, заманчалаштырылган гамәлдәге төп фондлар һәм әйләнештәге чаралар, кыйммәтле кәгазьләр, акчалата максатчыл кертемнәр, фәнни-техник продукция, акыл хәзинәләренә хокуклар, җир һәм Татарстан Республикасының башка табигый байлыклары һәм башка мөлкәти хокуклар чит ил инвестицияләренең объектлары була алалар.

Санитария-гигиена, экология таләпләренә һәм гамәлдәге законнарда билгеләнгән башка нормаларга туры килмәслек итеп төзелүче һәм файдаланылучы объектларны, шулай ук гражданнарның

һәм Татарстан Республикасындагы хокукый затларның закон тарафыннан сакланылучы хокукларына һәм мәнфәгатьләренә зыян китерүче объектларны инвестицияләү тыела.

Татарстан Республикасы Югары Советы Татарстан Республикасы Хөкүмәте тәкъдиме нигезендә чит ил инвестицияләре өчен чикләнелүче һәм тыелучы объектларны, шулай ук өстенлекле тармакларны һәм территорияләрне билгели.

5 статья. Чит ил инвестицияләрен гамәлгә ашыру

Инвестицияләрне гамәлгә ашыруның юнәлешләрен, рәвешләрен һәм күләмнәрен чит ил инвесторлары мөстәкыйль рәвештә билгелиләр.

Чит ил инвесторлары Татарстан Республикасы гражданнарын һәм хокукый затларын шартнамә нигезендә инвестиция эшчәнлеге белән шөгыльләнүгә җәлеп итәргә, шулай ук шартнамә буенча үз милкен биләү, файдалану һәм аңа хуҗа булу хокукын аларга тапшырырга, гамәлдәге законнарда тыелмаган башка гамәлләр кылырга хаклы.

Татарстан Республикасы территориясендә чит ил инвесторлары әлеге Законда һәм башка закон актларында күрсәтелгән гарантияләрдән файдаланалар. Татарстан Республикасы Хөкүмәте хокукый затлар белән чит ил инвесторлары арасындагы мөнәсәбәтләргә кагылышлы йөкләмәләрне үз өстенә алырга (гарантияләр бирергә) мөмкин.

## 2 бүлек

### Чит ил инвестицияләрен яклауның дәүләт гарантияләре һәм чит ил инвесторлары өчен ташламалар

<u>6 статья.</u> Чит ил инвестицияләренең хокукый режимы

Татарстан Республикасы территориясендә чит ил инвестицияләре хокукый яклаудан тулысынча һәм һичшиксез файдаланалар, аны әлеге Закон, Татарстан Республикасы территориясендә гамәлдә булган башка закон актлары һәм халыкара шартнамәләр тәэмин итә. Чит ил инвестицияләренең, шулай ук чит ил инвесторларының аларны гамәлгә ашыру эшчәнлегенең хокукый режимы Татарстан Республикасы хокукый затларынын һәм гражданнарының мәлкәтләре, мәлкәти хокуклары һәм инвестиция эшчәнлеге режимыннан уңайсызрак булмаска тиеш.

Татарстан Республикасы өчен аеруча әһәмияткә ия булган халык хуҗалыгы тармакларында чит ил инвесторлары эшчәнлеге өчен махсус режим тудырылырга мөмкин.

<u>7 статья.</u> Мөлкәтне мәҗбүри тартып алулардан, шулай ук дәүләт органнарының һәм аларның урындагы затларының законсыз гамәлләреннән гарантияләр

Әгәр Татарстан Республикасындагы гамәлдәге законнарда башкасы каралмаган булса, Татарстан Республикасында чит ил инвестицияләре национализацияләнмиләр, реквизицияләнмиләр яисә

конфискацияләнмиләр.

Национализацияләнгән яисә реквизицияләнгән очракларда чит ил инвесторларына бик тиз шуңа тиңдәш һәм отышлы компенсация түләнә.

Национализация турындагы карарларны Татарстан Республикасы Югары Советы кабул итә. Реквизицияләү һәм конфискацияләү хакындагы карарлар Татарстан Республикасы территориясендә гамәлдә булган законнарда билгеләнгән тәртиптә кабул ителә.

Чит ил инвестицияләре реквизицияләнмиләр, моңа табигый бәла-казалар, һәлакәтләр, эпидемияләр, эпизоотияләр һәм гадәттән тыш рәвештәге башка очраклар керми.

Чит ил инвесторлары Татарстан Республикасы дәүләт органнарының яисә аларның урындагы затларының законсыз гамәлләре аркасында, шулай ук әлеге органнарының яисә аларның урындагы затларының законнарда күрсәтелгән вазыйфалары тиешенчә башкармаулары аркасында китерелгән зыянны, табыш югалтуларын да кертеп, түләтергә хаклы.

<u>8 статья.</u> Чит ил инвесторларына компенсацияләр түләү һәм аларның югалтуларын каплау

Чит ил инвесторына түләнүче компенсация национализацияләү яисә реквизицияләү турында карар кабул итү мизгелендә национализацияләнүче яисә реквизицияләнүче инвестицияләрнең базар хакына тәңгәл килергә тиеш.

Национализацияләү яисә реквизицияләү турындагы карарны кабул иткәндә әлеге мәҗбүри чараларны гамәлгә ашыручы дәүләт органнары тартып алынучы инвестицияләр хакын бәяләү өчен бәй-

сеә вәкаләтле орган яисә учреждение билгеләп куялар.

Компенсация үз вакытында, тоткарланмыйча, башлангыч чорында чит ил инвестицияләре кертелгән валютада яисә чит ил инвесторы риза булырлык башка валютада түләнергә тиеш.

Татарстан Республикасы территориясендә гамәлдә булган процент ставкасы нигезендә национализацияләү яисә реквизицияләү турында карар кабул ителгән көннән компенсация түләнүче көнгә кадәр исәпләнелгән процент компенсациягә кертелә. Мондый ставка булмаган очракта Татарстан Республикасының Милли банкы кулланучы процент гамәлдә була.

Национализацияләү яисә реквизицияләү аркасында чит ил инвесторына китерелгән зыян, табыш югалтуларын да кертеп, Татарстан Республикасы Хөкүмәте тарафыннан республика бюджеты исәбеннән түләнелә.

Татарстан Республикасы дәүләт органнарының яисә аларның урындагы затларының законсыз гамәлләре аркасында, шулай ук әлеге органнарның яисә аларның урындагы затларының законнарда күрсәтелгән вазыйфаларын тиешенчә башкармаулары аркасында чит ил инвесторына китерелгән зыянны каплау, киләчәктә зыян китерүдә гаепле дәүләт органнары акчаларын бюджетка кертү шарты белән, республика бюджеты хисабыннан башкарыла.

<u>9 статья.</u> Чит ил инвестицияләренә кагылышлы түләүләрне күчерүнең гарантияләре

Тиешле салымнарын һәм җыемнарын түләгәннән соң чит ил инвесторларына үзләре гамәлгә ашыручы инвестицияләргә кагылышлы түләүләрне чит илгә каршылыксыз күчерү гарантияләнә, әгәр ту-

ләүләр чит ил валютасында һәм түбәндәгеләрдән алынган булса:

табыш, табыш өлеше, дивидендлар, процентлар, рөхсәт кәгазе түләүләре һәм комиссия түләүләре, техник ярдәм һәм техник хезмәт күрсәтү өчен түләүләр һәм башка түләүләр рәвешендә алынган инвестицияләрнең керемнәреннән;

икътисадый әһәмияте булган шартнамә йөкләмәләренең үтәлешен таләп итү һәм акча таләп итү хокуклары нигезендә түләнелүче суммалардан;

инвестицияләрне өлешчә яисә тулысынча туктату яки сату белән бәйле инвесторларга кергән суммалардан;

әлеге Законның 8 статьясында күрсәтелгән компенсацияләрдән.

<u>10 статья.</u> Татарстан Республикасы территориясендәге Россия Федерациясе валютасында түләүләрдән файдалану гарантияләре

Әлеге Законның 9 статьясында күрсәтелгән һәм чит ил инвесторлары тарафыннан Татарстан Республикасы һәм БДБнең рубльне милли валюта итеп кулланучы башка республикалары территориясендәге чыганаклардан рубльләрдә алынган түләүләр Татарстан Республикасы территориясендә яңадан инвестицияләнергә һәм Татарстан Республикасы территориясендә гамәлдә булган законнар нигезендә файдаланылырга мөмкин.

Чит ил инвесторлары акчаларын Россия Федерациясе валютасында саклау өчен Татарстан Республикасы территориясендәге Россия Федерациясенең Үзәк банкы лицензиясе булган банкларда агымдагы һәм исәп-хисап счетлары булдыра алалар, әмма акчала-

рын әлеге счетлардан чит илләргә күчерә алмыйлар.

Чит ил инвесторлары Татарстан Республикасы территориясендә гамәлдә булган законнарда күрсәтелгән тәртиптә мондый счетлардагы рубльләрен эчке валюта базарында чит ил валютасы сатып алу өчен куллана алалар.

11 статья. Законнар үзгәргән очраклардагы гарантияләр

Татарстан Республикасы чит ил инвесторлары хокукларының һәм чит ил инвестицияләре шартларының тотрыклылыгын гарантияли.

Чит ил инвесторларының хәлен һәм аларның коммерция эшчәнлеге шартларын начарайтучы нигезләмәләре булган закон актлары кабул ителсә, алар басылып чыкканнан соң өч ел үткәч кенә әлеге нигезләмәләр Татарстан Республикасы территориясендә инвестиция эшчәнлеге белән шөгыльләнүче чит ил инвесторларына карата кулланыла.

Күрсәтелгән нигезләмә саклануны (оборонаны), милли иминлекне һәм җәмәгать тәртибен тәэмин итү турындагы, стратегия әһәмиятенә ия булган һәм рөхсәт ителгән чимал әйберләрен экспортлау һәм импортлау турындагы, тирә-як мохитне саклау турындагы законнарның, шулай ук гайре монополия турындагы законнарның үзгәрү очракларына кагылмый.

12 статья. Инвестиция эшчәнлеге туктатылганда гарантияләр

Инвестиция эшчәнлеге туктатылганда, чит ил инвесторы үзе керткән инвестиция чараларын һәм аңа карата алынган керемнәрне акчалата яисә товарлата инвестиция эшчәнлеге туктатылган мизгелдәге базар бәяләрендә кире кайтарып алырга хаклы, моңа чит ил инвесторларының үзләре яисә алар катнашуындагы гамәлләр аркасында югалган, кулланылган суммалар һәм башка матди байлыклар керми.

13 статья. Чит ил инвестицияләрен хуплау

Чит ил инвесторларына карата чит ил инвестицияләрен хуплау буенча законда билгеләнгән тәртиптә түбәндәге чаралар кулланылырга мөмкин:

- салым салу өлкәсендәге чаралар: ташламалы салым ставкалары, салым түләүдән вакытлыча азат итү, салымнарны түләтмәү, салым түләүне кичектерү, тизләтелгән амортизация, җәмгыяви иминлек кертемнәренә һәм инвестиция резервларына кагылышлы башка чаралар;

- финанс чаралары: ташламалы заемнар (кредитлар), заемны гарантияләү;

- бурычларны акцияләргә конверсияләү (бурычны чит ил инвесторлары җыючы табыштан вексельләр рәвешендә процентларын хисаплап түләү);

- башка финанс булмаган чаралар: инфраструктураны төзү буенча ярдәм, кайбер хезмәт күрсәтүләрне ташламалы шартларда башкару турында хөкүмәт контрактлары һәм башка кайбер хезмәт

күрсәтүләре.

14 статья. Чит ил инвесторларының өстәмә салым ташламаларына һәм гарантияләргә хокуклары, инвестиция проектларын хуплау гамәлләре

Халык хуҗалыгында аеруча әһәмияткә ия булган инвестиция проектлары буенча чит ил инвесторлары, әлеге проектлар Татарстан Республикасы Хөкүмәте тарафыннан хупланган очракта, өстәмә ташламалар һәм дәүләт гарантияләре алырга хаклы.

Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең хуплавына ирешкән инвестиция проектлары "хупланылган инвестиция проекты" статусын алучы инвестиция проекты турындагы карар нигезендә раслана.

"Хупланылган инвестиция проекты" статусын алган инвестиция проектларына гамәлдәге закон чикләрендә ташламалы салым режимы һәм Хөкүмәтнең әлеге Законда каралган инвестицияләрдән гайреләрен яклауны тәэмин итүче махсус гарантияләре билгеләнә.

Чит ил инвестицияләренең проектлары "хупланылган инвестиция проекты" статусын алу өчен, Татарстан Республикасы Хөкүмәте раслаганчы, Ведомствоара эксперт комиссиясенең яисә шуңа вәкаләтле башка махсус органның дәүләт экспертизасын үтәргә тиеш.

Чит ил инвестицияләренең проектларына дәүләт экспертизасы, инвестиция эшчәнлеген оештыруларның рәвешенә карамастан, түбәндәге документлар булган очракта гына үткәрелергә мөмкин:

- инвестиция проектына дәүләт экспертизасын үткәрүне үтенеп язган чит ил инвесторы гаризасы, анда чит ил инвесторының хокукый адресы һәм хокукый статусы күрсәтелә;

- уртак ысулият нигезендә эшләнгән инвестиция проектының тасвирламасы һәм техник-икътисадый дәлилләү, инвестицияләрнең оештыру-хокукый рәвеше, инвестиция мөлкәте, инвестицияләрнең хакы, инвестицияләрнең эшче күләмнәре (агымдагы һәм озакка сузылган), инвестицияләрне урнаштыру керә.

Ведомствоара эксперт комиссиясе яисә шуңа вәкаләтле башка махсус орган гариза бирелгән мизгелдән соң утыз көн эчендә бәяләмәне Татарстан Республикасы Хөкүмәтенә кертергә тиеш.

15 статья. Мөлкәтне иминләштерү һәм хәвеф-хәтәрдән иминлек

Әгәр Татарстан Республикасы территориясендә гамәлдә булган законнарда мәҗбүри иминлек каралмаган булса, чит ил инвестицияләре булган предприятиеләрнең мөлкәтен һәм аларны хәвеф-хәтәрдән иминләштерүне предприятиеләр үзләре теләгәнчә башкара.

Мөлкәтне һәм эшчәнлекне иминләштерү белән бәйле чыгымнарның бер өлеше Татарстан Республикасы Хөкүмәте карамагы буенча Татарстан Республикасы Югары Советы билгеләгән чикләрдә республика бюджеты хисабына хупланырга мөмкин.

## 3 бүлек

### Чит ил инвестицияләре булган предприятиеләрне оештыру һәм ябу

16 статья. Чит ил инвестицияләре булган предприятиеләрнең оештыру-хокукый рәвешләре һәм төрләре

Чит ил инвестицияләре булган предприятиеләр Татарстан Республикасы территориясендә акционер җәмгыятьләр, ширкәтләр һәм Татарстан Республикасы территориясендә гамәлдә булган законнарда күрсәтелгән башка оештыру-хокукый рәвешләрдә төзеләләр һәм эшлиләр.

Татарстан Республикасы территориясендә түбәндәге предприятиеләр оештырылырга һәм эшләргә мөмкин:

чит ил инвестицияләре өлешчә катнашкан (катнаш капиталлы) предприятиеләр, шулай ук аларның ярдәмче предприятиеләре һәм филиаллары;

чит ил инвестицияләренеке генә булган предприятиеләр, шулай ук аларның ярдәмче предприятиеләре, филиаллары һәм башка аерымланган бүлекчәләре;

чит ил хокукый затларының филиаллары.

Чит ил инвестицияләре булган банкларны оештыру үзенчәлекләре банклар һәм банк эшчәнлеге турында Татарстан Республикасы территориясендә гамәлдә булган законнар тарафыннан билгеләнә.

17 статья. Чит ил инвестицияләре булган предприятиеләрне оештыру тәртибе

Чит ил инвестицияләре булган предприятие йә аны гамәлгә кую юлы белән, йә чит ил инвесторы тарафыннан элегрәк чит ил инвестицияләресез генә гамәлгә куелган предприятиенең катнашу өлешен (паен, акцияләрен) чит ил инвесторы сатып алу нәтиҗәсендә яисә мондый предприятиене тулысынча сатып алу юлы белән оешырга мөмкин.

Әлеге Законда күрсәтелгән тәртип нигезендә теркәлергә тиешле чит ил инвестицияләре булган предприятиеләр устав фондының минималь күләме Татарстан Республикасы Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә.

Чит ил инвестицияләре булган предприятие Татарстан Республикасы территориясендә гамәлдә булган законнарда билгеләнгән тәртиптә гамәлгә куела.

Элегрәк чит ил инвестицияләресез генә гамәлгә куелган предприятиенең өлешен (паен, акцияләрен) сатып алу, шулай ук мондый предприятиене тулысынча сатып алу Татарстан Республикасы территориясендә гамәлдә булган законнарда күрсәтелгән тәртиптә башкарыла.

18 статья. Чит ил инвестицияләре булган предприятиеләрне экспертизалау

Чит ил инвестицияләре булган эре масштаблы төзелешләр алып бару яисә аларны үзгәртеп кору белән бәйле предприятиеләрне оештырганда, шулай ук экологик йогынтысы булган проект-

ларны төзегәндә алдан дәүләт экспертизасы үткәрелә.

Кирәк очракларда чит ил инвестицияләре булган предприятиеләрне оештыру санитария-эпидемиология хезмәтенең тиешле бәяләмәсе булуын һәм экология экспертизасы үткәрүне таләп итә. Экспертизаларның барлык төрләре һәм рөхсәтләр бирү Татарстан Республикасы территориясендә гамәлдә булган законнар нигезендә гомуми тәртиптә башкарыла.

<u>19 статья.</u> Чит ил инвестицияләре булган предприятиеләрне гамәлгә кую документлары

Предприятие эшчәнлегенең асылын һәм максатларын, катнашучыларның составын, устав фондының күләмен, оештыру вакытын һәм тәртибен, шул исәптән чит ил валютасында катнашучылар өлешенең күләмен, аларның кертелү һәм бәяләнү тәртибен, табышның бүленеш тәртибен, идарә органнарының төзелешен, составын һәм вәкаләтләрен, карарларны кабул итү тәртибен, уртак килешүне таләп итүче мәсьәләләрнең исемлеген, предприятиене ябу тәртибен чит ил инвестицияләре булган предприятиеләрне гамәлгә кую документлары билгеләргә тиеш. Моннан тыш, гамәлгә кую документларына Татарстан Республикасы территориясендә гамәлдә булган законнарга каршы килмәүче һәм предприятие эшчәнлегенең үзенчәлекләрен чагылдыручы башка нигезләмәләр дә кертелергә мөмкин.

Устав фондына кертемнәрне бәяләү рубльләрдә дә, түләүләрне һәм кертемнәрне башкару чорындагы Россия Федерациясе Үзәк банкы курсы буенча яңадан исәпләнеп, чит ил валютасында да башкарылырга мөмкин.

Чит ил инвестицияләре булган предприятиенең устав фондына мөлкәт рәвешендәге кертемнәр дөнья базары бәяләре нигезендә катнашучылар арасындагы килешү буенча бәяләнә. Мондый бәяләр булмаганда, кертемнәрнең хакы катнашучылар килешкәнчә билгеләнә.

<u>20 статья</u>. Чит ил инвестицияләре булган предприятиеләрнең ярдәмче предприятиеләре

Чит ил инвестицияләре булган предприятиеләр Татарстан Республикасында һәм аннан читтә дә ярдәмче предприятиеләр төзи ала.

Татарстан Республикасы территориясендә ярдәмче предприятиеләр республика территориясендә гамәлдә булган законнар нигезендә хокукый зат буларак төзелә.

<u>21 статья.</u> Чит ил инвестицияләре булган предприятиеләрнең филиаллары һәм вәкиллекләре

Чит ил инвестицияләре булган предприятие Татарстан Республикасы территориясендә һәм аннан читтә дә филиаллар, вәкиллекләр һәм башка аерымланган бүлекчәләр төзи ала.

Татарстан Республикасы территориясендә филиаллар, вәкиллекләр һәм башка аерымланган бүлекчәләр гамәлдәге законнарда предприятиене төзү өчен билгеләнгән шартларны үтәгән тәкъдирдә төзелә. Алар хокукый зат булмыйлар, алар хакында гамәлгә куючы предприятие раслаган нигезләмәләргә таянып эш итәләр һәм Татарстан Республикасының банк учреждениеләрендә исәп-хисап ачарга хаклылар.

22 статья. Чит ил инвестицияләре булган предприятиеләрнең берләшмәләре

Чит ил инвестицияләре булган предприятиеләр Татарстан Республикасы территориясендә гамәлдә булган законнарда каралган шартларда һәм тәртиптә берлекләргә, ассоциацияләргә, концернларга, консорциумнарга, тармакара, төбәк һәм башка төрле берләшмәләргә, шул исәптән Татарстан Республикасының хокукый затларын катнаштырып та, берләшергә мөмкин, шулай ук алар элек төзелгән берләшмәләргә дә керә алалар.

23 статья. Чит ил инвестицияләре булган предприятиеләрне дәүләт тарафыннан теркәү

Чит ил инвестицияләре булган предприятие дәүләт тарафыннан теркәлергә тиеш, бу гамәлне шуңа вәкаләтле дәүләт органы башкара, һәм ул теркәлгән мизгеленнән Татарстан Республикасы законнары нигезендә хокукый зат хокукларына ия була.

Чит ил инвестицияләре булган предприятиеләрне дәүләт тарафыннан теркәү түбәндәге документлар булганда гына гамәлгә ашырыла:

Катнаш капиталы булган предприятиеләр өчен:

а) гамәлгә куючыларның оештырылучы предприятиене теркәү хакында үтенече булган язма гаризалары;

б) гамәлгә куючы документларның нотариус раслаган ике нөсхә күчермәсе;

в) мөлкәт хуҗасының яисә шул турыда мөлкәтче тарафыннан вәкаләт бирелгән органның предприятие төзү турында карары;

г) Татарстан Республикасы хокукый затының уртак предприятиесен оештыруда һәр катнашучының гамәлгә кую документларыннан нотариус раслаган күчермәләр;

д) чит ил инвесторының түләү сәләтен раслаучы документ, әлеге документны аңа хезмәт күрсәтүче банк яисә башка кредит-финанс учреждениесе биргән булырга тиеш (урысчага тәрҗемәсенең дөреслеге чит ил инвесторы теркәлгән илдәге Россиянең консуллык учреждениеләрендә расланган булырга тиеш);

е) чит ил инвесторы чыккан илнең сәүдә реестрыннан өземтәләр яисә чит ил инвесторы төпләнгән, гражданлыгы булган яки даими яшәгән илдәге законнар нигезендә аның хокукый статусын раслаучы шуңа тиңдәш башка документ (урысчага тәрҗемәсенең дөреслеге чит ил инвесторы теркәлгән илдәге Россиянең консуллык учреждениеләрендә расланган булырга тиеш);

ж) законда каралган очракларда эксперт бәяләмәләре.

Тулысынча чит ил инвесторларыныкы булган предприятиеләр өчен:

а) чит ил инвесторының теркәүне үтенеп язган гаризасы;

б) уставның нотариус раслаган ике нөсхә күчермәсе;

в) чит ил инвесторының түләү сәләтен раслаучы документ, әлеге документны аңа хезмәт күрсәтүче банк яисә башка кредит-финанс учреждениесе биргән булырга тиеш (урысчага тәрҗемәсенең дөреслеге чит ил инвесторы теркәлгән илдәге Россиянең консуллык учреждениеләрендә расланган булырга тиеш);

г) чит ил инвесторы чыккан илнең сәүдә реестрыннан өземтәләр (урысчага тәрҗемәсенең дөреслеге чит ил инвесторы теркәлгән илдәге Россиянең консуллык учреждениеләрендә расланган булырга тиеш);

д) законда каралган очракларда эксперт бәяләмәләре.

Чит ил инвестицияләре булган предприятиеләрнең филиаллары һәм чит илләрнең хокукый затларының филиаллары өчен:

а) филиал оештыручы предприятие җитәкчесенең филиалны теркәүне үтенеп язган имзалы гаризасы;

б) филиал оештыру турында предприятие идарәсенең вәкаләтле органы карарыннан өземтә;

в) филиал хакында нигезләмәнең нотариус раслаган ике нөсхә күчермәсе;

г) филиал оештыручы предприятиенең гамәлгә кую документларыннан нотариус раслаган күчермәләр;

д) чит илнең хокукый заты өчен - чит ил инвесторы чыккан илнең сәүдә реестрыннан өземтә яисә чит ил инвесторы тупланган илнең законнары нигезендә аның хокукый статусын раслаучы шуңа тиңдәш башка документ (урысчага тәрҗемәсенең дөреслеге чит ил инвесторы теркәлгән илдәге Россиянең консуллык учреждениеләрендә расланган булырга тиеш);

е) законда каралган очракларда эксперт бәяләмәләре.

Электән теркәлгән чит ил инвестицияле предприятиеләрнең һәм аларның филиалларының гамәлгә кую документларындагы устав фонды күләмен үзгәртүгә, эшчәнлектә катнашучыларның һәм предметларның составына кагылышлы һәр мәгънәви үзгәреш һәм өстәмә, аларны ябу турындагы белешмә дәүләт тарафыннан теркәлергә тиеш.

Гамәлгә кую документларына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында предприятиенең вәкаләтле органы карарының нотариус раслаган күчермәсен чит ил инвестицияләре булган предприятие карар кабул ителгәннән соң 30 көннән дә соңга калмыйча теркәү-

че органга илтергә тиеш. Гамәлгә кую документларындагы әлеге үзгәрешләр һәм өстәмәләр теркәлгәннән соң гына үз көченә керә.

Чит ил инвестицияләре булган предприятиеләрне теркәү хакындагы белешмәләр Татарстан Республикасының Дәүләт реестрына кертелә.

Устаф фонды билгеләнгәннән кимрәк булган чит ил инвестицияле предприятиеләр өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәте тарафыннан Татарстан Республикасында гамәлдә булган законнарда билгеләнә торган теркәлүнең гадиләштерелгән тәртибе кулланыла.

<u>24 статья</u>. Чит ил инвестицияләре булган предприятиеләрне теркәү вакыты

Дәүләтнең вәкаләтле органы гариза биргәннән соң 21 көн эчендә чит ил инвестицияләре булган предприятиене теркәргә яисә гариза бирүчегә теркәүдән баш тарту хакында хәбәр итәргә тиеш.

Чит ил инвестицияле теркәлгән предприятиегә теркәлү турында мәгълүм үрнәктәге таныклык бирелә. Дәүләт тарафыннан теркәлгәннән соң чит ил инвестицияләре булган предприятие оешкан дип санала. Теркәлү турындагы мәгълүмат җирле администрациягә хәбәр ителә. Теркәлү хакындагы хәбәр матбугатта басыла.

<u>25 статья.</u> Чит ил инвестицияләре булган предприятиеләрне теркәүдән баш тарту

Бары тик предприятиене оештыру буенча Татарстан Республикасы территориясендә гамәлдә булган законнарда билгеләнгән

че органга илтергә тиеш. Гамәлгә кую документларындагы әлеге үзгәрешләр һәм өстәмәләр теркәлгәннән соң гына үз көченә керә.

Чит ил инвестицияләре булган предприятиеләрне теркәү хакындагы белешмәләр Татарстан Республикасының Дәүләт реестрына кертелә.

Устаф фонды билгеләнгәннән кимрәк булган чит ил инвестицияле предприятиеләр өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәте тарафыннан Татарстан Республикасында гамәлдә булган законнарда билгеләнә торган теркәлүнең гадиләштерелгән тәртибе кулланыла.

24 статья. Чит ил инвестицияләре булган предприятиеләрне теркәү вакыты

Дәүләтнең вәкаләтле органы гариза биргәннән соң 21 көн эчендә чит ил инвестицияләре булган предприятиене теркәргә яисә гариза бирүчегә теркәүдән баш тарту хакында хәбәр итәргә тиеш.

Чит ил инвестицияле теркәлгән предприятиегә теркәлү турында мәгълүм үрнәктәге таныклык бирелә. Дәүләт тарафыннан теркәлгәннән соң чит ил инвестицияләре булган предприятие оешкан дип санала. Теркәлү турындагы мәгълүмат дәүләт хакимиятенең җирле органнарына хәбәр ителә. Теркәлү хакындагы хәбәр матбугатта басыла.

25 статья. Чит ил инвестицияләре булган предприятиеләрне теркәүдән баш тарту

Бары тик предприятиене оештыру буенча Татарстан Республикасы территориясендә гамәлдә булган законнарда билгеләнгән

тәртипне бозган очракта яисә теркәлү өчен кирәкле документлар булмаганда гына чит ил инвестицияләре булган предприятиене дәүләт тарафыннан теркәүдән баш тартырга мөмкин. Теркәүдән баш тартуга каршы хөкем тәртибендә шикаять белдерелергә мөмкин.

26 статья. Чит ил инвестицияләре булган предприятиеләрнең эшчәнлеген туктату

Чит ил инвестицияләре булган предприятиенең эшчәнлеге ябу яисә үзгәртеп кору рәвешендә туктатыла.

Чит ил инвестицияләре булган предприятиене үзгәртеп кору гамәлдәге законнар нигезендә икесен бер итү, кушу, бүлү, башка оештыру-хокукый рәвешкә үзгәртү юлы белән гамәлгә ашырыла.

Чит ил инвестицияләре булган предприятие Татарстан Республикасы территориясендә гамәлдә булган законнарда каралган очракларда һәм тәртиптә ябыла.

Чит ил инвестицияләре булган предприятие теркәлгәннән соң бер ел узгач, һәр катнашучы тарафыннан устав фондына гамәлгә кую документларында күрсәтелгән кертемнең 50 процентыннан да ким булмаган өлеше кертелү хакында документ нигезендә раслау булмаса, әлеге предприятиене теркәгән орган предприятие үз эшчәнлеген дәвам итәрлек хәлдә түгел дип таный һәм аны ябу турында карар кабул итә. Бу турыда мәгълүматлар матбугатта басыла. Кертемнәр кертү вакыты Татарстан Республикасы Хөкүмәте тарафыннан озайтылырга мөмкин.

Чит ил инвестицияләре булган предприятиене ябу турындагы карар ябу комиссиясе акты нигезендә кабул ителә.

Чит ил инвестицияләре булган предприятиене ябу турында карарга хөкем тәртибендә шикаять белдерелергә мөмкин.

## 4 бүлек

## Чит ил инвестицияләре булган предприятиеләрнең эшчәнлек төрләре һәм шартлары

<u>27 статья.</u> Эшчәнлек төрләре

Чит ил инвестицияләре булган предприятие, гамәлдәге законнарда тыелган эшчәнлектән гайре, үз уставында каралган барлык төр эшчәнлекне башкара ала.

Чит ил инвестицияләре булган предприятиеләрнең махсус рөхсәт (лицензия) нигезендә генә гамәлгә ашырыла торган эшчәнлек төрләренә законнарда билгеләнгән тәртиптә тиешле рөхсәт кәгазе бирү зарур. Рөхсәт кәгазеннән гайре башкарылган эшчәнлектән алынган керемнәр җирле бюджетка күчерелә.

<u>28 статья.</u> Товарларны һәм хезмәт күрсәтүләрне экспортлау һәм импортлау

Тулысынча чит ил инвесторларына караган предприятиеләр һәм чит ил инвестицияләре булган предприятиеләр Татарстан Республикасы территориясендә гамәлдә булган законнарда билгеләнгән тәртиптә һәм шартларда үзләре җитештергән продукцияне экспортка чыгара алалар һәм үзләренә кирәкле продукцияне импортлый алалар.

Таможняны җайга салу Татарстан Республикасы территориясендә гамәлдә булган законнар нигезендә башкарыла.

29 статья. Чит ил инвестицияләре булган предприятиеләрдә тизләтелгән амортизация

Татарстан Республикасы Хөкүмәте чит ил инвестицияләре булган предприятиеләргә тизләтелгән амортизацияләү мөмкинлеге бирә ала (амортизация кертемнәренең арттырылган нормативларын куллану).

Тизләтелгән амортизацияләү тәртибе һәм шартлары Татарстан Республикасы Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә. Гаризада күрсәтелгән вакыты узганчы хокукый затның чит ил инвестицияләре белән катнаш эшчәнлеге туктатылган очракта, тизләтелгән амортизация нәтиҗәсендә җыелган сумма тиешле бюджетка күчерелә.

30 статья. Салым салу

Чит ил инвестицияләре булган предприятиеләр, шулай ук чит ил инвесторлары салым түлиләр һәм Татарстан Республикасы территориясендә гамәлдә булган законнарда билгеләнгән барлык ташламалардан файдалана алалар.

31 статья. Салым салу максатларында тикшерү үткәрү

Чит ил инвестицияләре булган предприятиеләрнең финанс һәм сәүдә эшчәнлегенә салым салу максатларында тикшерүне Татарстан Республикасының шуңа вәкаләтле дәүләт органнары үткәрә.

Чит ил инвестицияләре булган предприятиеләрнең теләге буенча, мөлкәтне һәм эшчәнлекне анализлау максатларында тикшерүне Татарстан Республикасының аудитор оешмалары да, шулай ук чит илләрнең аудитор оешмалары да үткәрә ала.

32 статья. Бухгалтер хисаплары һәм хисап тоту

Татарстан Республикасы территориясендә чит ил инвестицияләре булган предприятиеләрнең бухгалтер хисаплары һәм хисап тотуы республикада билгеләнгән кагыйдәләр нигезендә алып барыла, ә теләгәндә, чит ил инвесторы илендәге гамәлдә булган кагыйдәләр буенча да башкарылырга мөмкин.

Нисбәт бәяләмәсе бирү һәм исәпләү максатларында чит ил инвестицияләре булган предприятие Россия Федерациясе Үзәк банкы курсы буенча чит ил валютасын рубльгә күчереп, яңадан исәпләүне гамәлгә ашыра.

33 статья. Йөкләмәләрне үтәү

Чит ил инвестицияләре булган предприятие үз мөлкәтен йөкләмәләренең һәр төрен үтәү өчен файдалана ала. Йөкләмәләрен үтәгәндә ул мөлкәти хокукларыннан файдаланырга мөмкин.

34 статья. Финанс,кредит, исәп-хисап һәм валюта гамәлләре

Чит ил инвестицияле предприятиеләр финанс, кредит һәм исәп-хисап гамәлләрен Татарстан Республикасында гамәлдә булган законнар нигезендә башкаралар. Чит ил валютасында башкарылучы

гамәлләрне чит ил инвестицияләре булган предприятиеләр Татарстан Республикасы территориясендә гамәлдә булган законнарда билгеләнгән тәртиптә тормышка ашыралар.

35 статья. Акыл милке хокукы

Чит ил инвестицияләре булган предприятиеләрнең акыл милке хокукларын саклау һәм аны тормышка ашыру Татарстан Республикасы территориясендә гамәлдә булган законнар һәм халыкара килешүләр нигезендә тәэмин ителә.

Чит ил инвестицияләре булган предприятиеләр үз хезмәткәрләре белән акыл милке объектлары хокуклары турында шартнамәләр төзиләр. Предприятиеләр уйлап табуны, сәнәгать үрнәген яисә товар тамгасын патент иясе - автор белән төзелгән шартнамәдәге шартларда кулланырга хаклы.

Уйлап табылган әйбергә, сәнәгать үрнәгенә, товар тамгасына һәм акыл милкенең башка объектларына патент хезмәткәр белән предприятие арасында тиешле шартнамә төзелгәч кенә предприятиегә бирелә.

Чит ил инвестицияләре булган предприятие үзенә караган уйлап табуларны һәм сәнәгать үрнәкләрен чит илләргә патентлау турында мөстәкыйль рәвештә карар кабул итә.

36 статья. Хезмәт мөнәсәбәтләре

Чит ил инвестицияләре булган предприятиеләр хезмәткәрләрне яллау һәм эштән азат итү, хезмәт һәм ял режимы, хезмәт өчен түләүнең шартлары, гарантияләр һәм компенсацияләр мәсьәләләрен

мөстәкыйль хәл итәләр. Бу очракта предприятие хезмәткәрләренең хәле Татарстан Республикасы территориясендә гамәлдә булган законнарда каралган шартлардан начараймаска тиеш. Хезмәт мөнәсәбәтләре күмәк шартнамә һәм шәхси хезмәт шартнамәләре (контрактлары) нигезендә җайга салына.

Чит ил инвестицияләре булган предприятиеләрнең эшчеләре һәм хезмәткәрләре составына, аларның идарә органнарына чит ил гражданнары да керергә мөмкин. Чит ил хезмәткәрләрен яллау, аларның хезмәт һәм ял шартлары, шулай ук аларның пенсия белән тәэмин ителеше һәрберсе белән шәхсән төзелгән хезмәт шартнамәсендә килештерелә. Чит ил хезмәткәрләренең чит ил валютасындагы хезмәт хаклары керемнән салым түләүләрен түләгәннән соң чит илгә күчерелә ала.

<u>37 статья.</u> Чит ил инвестицияләре булган предприятиеләрнең хезмәткәрләрен җәмгыяви иминләштерү һәм җәмгыяви тәэмин итү

Чит ил инвестицияләре булган предприятиеләрнең хезмәткәрләрен җәмгыяви иминләштерү һәм аларны җәмгыяви яктан тәэмин итү (чит ил хезмәткәрләрен пенсия белән тәэмин итүдән гайре) Татарстан Республикасы территориясендә гамәлдә булган законнардагы нормалар нигезендә җайга салына.

Чит ил инвестицияләре булган предприятиеләрнең чит ил хезмәткәрләрен пенсия белән тәэмин итүгә түләүләр алар даими яши торган илнең тиешле фондларына валюталата һәм шул илләрдә билгеләнгән шартларда күчерелә.

Чит ил инвестицияләре булган предприятиеләр хезмәткәрләр-

не дәүләт тарафыннан җәмгыяви иминләштерү буенча билгеләнгән кертемнәрне һәм пенсия белән тәэмин итү кертемнәрен Татарстан Республикасы предприятиеләре һәм оешмалары өчен билгеләнгән күләмнәрдә түлиләр.

38 статья. Чит ил инвестицияләре булган предприятиеләрнең эшчәнлеген тикшереп тору

Чит ил инвестицияләре булган предприятиеләрнең гамәлдәге законнарны үтәүләрен дәүләтнең шуңа вәкаләтле органнары үз вәкаләтләре чикләрендә тикшереп торалар. Шул ук вакытта дәүләтнең тикшереп торучы органнары чит ил инвестицияләре булган предприятиегә бирелгән хокукларны бозмаска, аның җитештерү эшчәнлегенә тыкшынмаска тиеш.

39 статья. Чит ил инвестицияләре булган предприятиеләрнең җаваплылыгы

Шартнамәләрдәге йөкләмәләрне, кредит, исәп-хисапны һәм салым түләүләрен үтәмәгән һәм тиешенчә үтәмәгән өчен, продукция сыйфатына карата таләпләрне, эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыруның билгеләнгән башка кагыйдәләрен бозган өчен чит ил инвестицияләре булган предприятие гамәлдәге законнар нигезендә җаваплы була.

Чит ил инвестицияләре булган предприятие үз мөлкәте кысаларында йөкләмәләре өчен җавап тота.

Татарстан Республикасы чит ил инвестицияләре булган предприятиенең йөкләмәләре өчен җавап бирми, ә чит ил инвести-

цияләре булган предприятие Татарстан Республикасы йөкләмәләре өчен җавап бирми.

## 5 бүлек

## Чит ил инвесторларының һәм чит ил инвестицияләре булган предприятиеләрнең милекче хокукына ия булулары

40 статья. Милекче хокукына ия булу

Чит ил инвесторлары һәм чит ил инвестицияләре булган предприятиеләр эшчәнлекләрендә максатларына ирешү өчен Татарстан Республикасы территориясендәге үзләренә кирәкле биналарны, корылмаларны, җиһазларны, күчерелүчән һәм күчерелмәүчән башка мөлкәтне Татарстан Республикасы законнары нигезендә үз милке итәргә хаклы.

41 статья. Катнашу өлешен, пайларны, акцияләрне һәм башка кыйммәтле кәгазьләрне сатып алу

Чит ил инвесторлары һәм чит ил инвестицияләре булган предприятиеләр Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан предприятиеләрдә катнашу өлешен, предприятиеләрнең пайларын, акцияләрен һәм башка кыйммәтле кәгазьләрен рубльләргә дә, чит ил валютасына да сатып ала алалар.

Катнашу өлешләрен, пайларны, акцияләрне һәм башка кыйммәтле кәгазьләрне сатып алуны шуңа вәкаләтле дәүләт органнары

теркәргә тиеш.

Дәүләтнең кыйммәтле кәгазьләрен сатып алу шуңа вәкаләтле дәүләт органы рөхсәте нигезендә гамәлгә ашырылырга мөмкин.

42 статья. Хосусыйлаштыруда катнашу

Чит ил инвесторлары гамәлдәге законнар нигезендә Татарстан Республикасы территориясендәге дәүләт һәм җирле предприятиеләрне, шулай ук төзелеп бетмәгән капитал төзелеш объектларын хосусыйлаштыруда катнаша алалар.

Чит ил инвестицияләре булган предприятиеләрнең хосусыйлаштыруда катнашуы Татарстан Республикасы территориясендә гамәлдә булган законнар нигезендә җайга салына.

43 статья. Җир кишәрлекләренә милекчелек хокукы һәм башка табигый байлыклардан файдалану хокукы

Җир кишәрлекләре чит ил инвесторлары һәм чит ил инвестицияләре булган предприятиеләр милкендә була ала.

Чит ил инвесторларының һәм чит ил инвестицияле предприятиеләрнең милкендәге кишәрлекләрнең табигый байлыкларыннан файдалану хокукы Татарстан Республикасы территориясендә гамәлдә булган законнар тарафыннан билгеләнә.

## 6 бүлек

## Бәхәсләрне хәл итү тәртибе

<u>44 статья.</u> Бәхәсләрне хәл итү тәртибе

Әгәр Татарстан Республикасының халыкара шартнамәсендә башка тәртип каралмаган булса, инвестиция бәхәсләрен, шул исәптән компенсацияләрнең күләме, шартлары яисә түләү тәртибе турындагы бәхәсләрне Татарстан Республикасы Югары суды яисә Татарстан Республикасы Югары арбитраж суды хәл итә.

Чит ил инвесторлары һәм чит ил инвестицияләре булган предприятиеләр белән Татарстан Республикасының дәүләт органнары, предприятиеләре, җәмәгать оешмалары һәм Татарстан Республикасының башка хокукый затлары арасындагы бәхәсләрне, инвесторлар белән чит ил инвестицияләре булган предприятиеләр арасында хуҗалык эшчәнлегенә кагылышлы мәсьәләләр хакындагы бәхәсләрне, шулай ук чит ил инвестицияләре булган предприятиедә катнашучылар белән предприятиенең үзе арасындагы бәхәсләрне Татарстан Республикасының Югары арбитраж суды яисә яклар килешүе буенча арадашчы суд яки алар билгеләгән башка орган карарга тиеш.

Татарстан Республикасының халыкара шартнамәсендә Татарстан Республикасы территориясендәге чит ил инвестицияләрен гамәлгә ашыру белән бәйле килеп чыга торган бәхәсләрне хәл итү буенча халыкара чараларга мөрәҗәгать итү дә каралырга мөмкин.

Татарстан Республикасы
Президенты                                        М.Шәймиев

Казан шәһәре,
1994 елның 19 июле
№2180- XII